СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

25.10.2018 — с. Введенская Слобода — № 60-263

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2017 елның 29 сентябрендәге 37-165 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7.3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы тулыландырырга:

«2.1.) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозуларны кылуның факттагы шартлары бәян ителә торган доклады һәм муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән генә язмача аңлату (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге хокук бозулардан тыш);

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов